СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

## КАРАР

« 22 » сентябрь 2017 ел № 39

### Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | - вак таш сатып алу, юл-урам челтәренә нигез салу һәм юл өслеген каплау буенча хезмәт күрсәтү:<br>Утар Аты авылы<br>9 Май ур.<br>Совет урамы<br>Комсомол урамы<br>Мәктәп урамы<br>Кооператив ур.,<br>Субаш Аты авылы<br>Кооператив ур.<br>Яңа урам |

| | | |
|---|---|---|
| | | 9 Май ур.<br>Тарлау ур.,<br>Орнашбаш авылы<br>Мичурин ур.<br>Яшел урам<br>Механизаторлар урамы<br>Тукай урамы<br>Клуб урамы<br>Яшьләр урамы<br>Комсомол урамы,<br>Югары Аты авылы<br>Кооператив ур.<br>Комсомол урамы<br>Мәктәп урамы,<br>Иске Җөлбә авылы<br>Үзәк ур.<br>9 Май ур.,<br>Кушлавыч авылы<br>8 Март ур. |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | - җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;:<br>Орнашбаш авылы<br>Иске Җөлбә авылы<br>Кушлавыч авылы |
| 3 | Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - материал алу, чишмә территориясен төзекләндерү;:<br>Кушлавыч авылы<br>- Орнашбаш авылында су башнясын сатып алу һәм урнаштыру |
| 4 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;:<br>Утар Аты авылы<br>Мәктәп урамы<br>Совет урамы<br>Комсомол урамы<br>Югары Аты авылы<br>Субаш Аты авылы<br>Орнашбаш авылы<br>Кушлавыч авылы<br>Иске Җөлбә авылы |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Утар-Аты авылы, Кооператив ур. 22 йорт.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Хәкимҗанов

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012621